**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№47** **09.12.2021**

**2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1 статья

1. 2022 елга Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 6118,5 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 6118,5 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 мең сум күләмендә.

2. 2023 һәм 2024 елларга Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2023 елга 6086,3 мең сум, 2023 елга 6090,3 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Сәвәлләй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2023 елга 6086,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 155,5 мең сум һәм 2024 елга 6090,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 304,9 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2023 елга 0 мең сум, 2024 елга 0 мең сум күләмендә.

3. Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең 2023 елның 1

гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең 2024 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең 2025 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга;

3 статья

Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетында 2022 елга, 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар планы чорына Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 5 кушымта нигезендә расларга.

2. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар планы чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 6 кушымта нигезендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2022 елга 0 мең сум, 2023 елга 0 мең сум, 2024 елга 0 мең сум.

5 статья

1. Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләрен Сәвәләй авыл җирлегендә яшәүчеләрне мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ялны оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен килешү нигезендә 2022 елга 3748,4 мең сум, 2023 елга 3695,1 мең сум, 2024 елга 3695,2 мең сум күләмендә расларга.

2. 2022-2024 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6 статья

Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге бюджетында 2022 елда җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Зәй муниципаль районы бюджетыннан 44,7 мең сум, 2023 елда-9,0 мең сум, 2024 елда-9,1 мең сум күләмендә дотация күләмен расларга.

7 статья

Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетында Зәй муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу өчен 103,8 мең сум, 2023 елда 107,3 мең сум, 2024 елда 111,2 мең сум күләмендә субвенцияләр күләмен расларга.

8 статья

Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 статья

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының Казначылык департаментының Зәй районы һәм Зәй шәһәре территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

10 статья

2022 нче елның 1 нче гыйнварына Сәвәләй авыл җирлеге бюджеты акчалары, 2021 нчы елда шушы муниципаль контрактлар нигезендә түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге исеменнән төзелгән, файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, 2022 елда Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

11 статья

Әлеге карарны җирле массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru/rus/savaleevskoe.htm адресы буенча урнаштырырга.

12 статья

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Совет рәисе,**
**Сәвәләй авыл авыл җирлеге башлыгы** **И.А.Галимов**